# МАНЗАРАС АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

## КАРАР

9 июнь 2021ел №11

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлешенең 20 пункты, Манзарас авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлеге Советы

К А Р А Р Б И Р Д Е :

1. «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы «Манзарас авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» Манзарас авыл җирлеге Советының 2014 елның 28 гыйнварындагы 1номерлы карары (2016 елның 16 декабрендәге 41 номерлы, 2019 елның 20 февралендәге 4 номерлы, 2019 елның 29 августындагы 21 номерлы Манзарас авыл җирлеге Советы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы «Манзарас авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең «Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә», 18.1 статьясын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә.

«18. 1. Җир кишәрлекләренең иң чик күләмнәре:

«Шәхси торак төзелеше», «шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен» рөхсәт ителгән файдалану рәвешендәге җир кишәрлекләренең минималь күләме – 1 000 кв.м.

«Шәхси торак төзелеше» рөхсәт ителгән файдалану рәвешендәге җир кишәрлегенең максималь күләме – 2500 кв.м, «шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен» – 5000 кв.м.»

2. Әлеге карарны махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Манзарас авыл җирлеге башлыгы Р. Г. Хәбибуллина

ОГРН 1021607752957
ИНН 1623001653